КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 апрель г.Казань № 386

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 февраль, 115 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 927 нче, 2018 ел, 10 май, 341 нче, 2020 ел, 11 февраль, 92 нче, 2021 ел, 5 апрель, 215 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 пунктта:

бишенче абзацта «йөк күтәрү* - 16 тоннага кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

«*Транспорт чарасының рөхсәт ителгән  максималь массасы һәм йөкләнешсез транспорт чарасының массасы арасындагы аерма буларак билгеләнә.» астөшермәсен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин